| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**04.11.2017 ел** | Зеленодольск шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 2779** |

Зеленодольск шәһәре, Украина урамы, 29 нчы йорт адресы буенча урнашкан җир кишәрлеген һәм анда урнашкан күчемсез мөлкәт объектларын кулланыштан алу турында

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 26 сентябрендәге 2178 номерлы карары белән расланган, Зеленодольск муниципаль районы муниципаль берәмлеге территориясендә 2013-2017 елларга Зеленодольск муниципаль районында авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча муниципаль адреслы программаны гамәлгә ашыру максатларында, «Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга ярдәм фонды турында» 2007 елның 21 июлендәге 185-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Торак, Җир кодекслары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Муниципаль ихтыяҗлар өчен Зеленодольск шәһәре, Украина урамы, 29 нчы йорт адресы буенча, авария хәлендәге һәм сүтелергә тиешле Украина урамындагы 29 нчы күп фатирлы торак йорт урнашкан җир кишәрлеген, шулай ук кушымтадагы исемлек (кушымта) буенча күрсәтелгән йортта урнашкан күчемсез мөлкәт объектларын (торак һәм торак булмаган биналарны) кулланыштан алырга.
2. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматы рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) һәм «Зеленодольская правда» газетасында урнаштырырга.
3. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О.А. Матвеевага әлеге карарның күчермәсен җибәрергә:

-кулланыштан алынган күчемсез мөлкәтнең хокук ияләренә;

- күчемсез мөлкәткә хокукларны һәм аның белән килешүләрне дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашыручы органга;

-МКУ « Торак сәясәте департаменты».

4. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән җир кишәрлеген урнаштыру схемасын «Зеленодольск муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МУ раслауны тәэмин итәргә.

5. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 14 июнендәге 1718 номерлы карары, объектның кадастр (яки шартлы) номеры 16:49:010504:49 булган, Зеленодольск шәһәре, Украина урамы, 29 нчы йорт, 9 нчы фатирын кулланыштан алу өлешендә, үз көчен югалткан дип танырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О.А.Матвеевага йөкләргә.

Җитәкче А.Х. Сәхибуллин

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты
______________________№_______________
карарына кушымта

Зеленодольск шәһәре, Украина урамы, 29 нчы күпфатирлы торак йортта урнашкан, авария хәлендә дип танылган һәм сүтелелергә тиешле кулланыштан алына торган күчемсез мөлкәт объектлары
(торак, торак булмаган биналар)
исемлеге.

| №кв. | Объектның кадрлар (яисә) шартлы номеры |
|---|---|
| 9 | 16:49:010504:49 |